ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**08.02.2022**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 235**

2022 елга гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт бәясенең максималь күләмен раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннары наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак - коммуналь хуҗалык министрлыгының 2021 елның 17 декабрендәге «Россия Федерациясе буенча торак урынның гомуми мәйданының 2022 елның беренче яртыеллыгына бер квадрат метрының бәясе нормативы һәм Россия Федерациясе субъектлары буенча 2022 елның I кварталына торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар хакы күрсәткечләре турында»» 955/пр номерлы боерыгы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Гражданнарны социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар дип тану турында карар кабул итү өчен 2022 елга гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт бәясенең максималь күләмен түбәндәгечә билгеләргә:

1.1. Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең максималь күләме:

1.1.1. ялгыз яшәүче граждан өчен – 42 097,33 руб.;

1.1.2. ике кешедән торган гаилә өчен – 42 097,33 руб.;

1.1.3. өч кешедән торган гаилә өчен – 42 097,33 руб.

1.2. Гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләме:

1.2.1. ялгыз яшәүче граждан өчен – 1 729 944 руб.;

1.2.2. ике кешедән торган гаилә өчен – 3 459 888 руб.;

1.2.3. өч кешедән торган гаилә өчен – 5 189 832 руб.;

1.2.4. дүрт кешедән торган гаилә өчен – 6 919 776 руб.;

1.2.5. биш кешедән торган гаилә өчен – 8 649 720 руб.;

1.2.6. алты кешедән торган гаилә өчен – 10 379 664 руб.;

1.2.7. җиде кешедән торган гаилә өчен – 12 109 608 руб.

2. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 01 июнендәге «2021 елның II кварталына гражданнар кеременең һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләмен раслау турында» 1207 номерлы карарын, 2021 елның 16 сентябрендәге «2021 елның III кварталына гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт бәясенең максималь күләмен раслау турында» 2269 номерлы карарын, 2021 елның 02 декабрендәге «2021 елның IV кварталына гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт бәясенең максималь күләмен раслау турында» 3085 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Гражданнарны социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар дип таныганда, «Зеленодольск муниципаль районының торак сәясәте департаменты» МКУ муниципаль торак фонды бүлегенә әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктларында күрсәтелгән күрсәткечләрне кулланырга.

4. Әлеге карарның гамәлдә булуын 2022 елның 01 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә таратырга.

5. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында һәм Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында(http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълумати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга .

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче И. Р. Ганиев